РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«31» март 2023 ел Олы Кайбыч ав. № 186

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 21 августындагы 291 номерлы Кайбыч муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигеәендә һәм муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 21 августындагы 291 номерлы Кайбыч муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче кушымтада:

2 пунктның 2.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Башкарма комитет җитәкчесе үз эшчәнлегендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы һәм  Башлыгы контролендә һәм аларга хисап тота»;

10 пунктның 5.1.1.1 һәм 5.1.3 пунктчаларында, 6.1 пунктында, 8 пунктның 8.1 пунктчасының 2 абзацында, 8.3 пунктчасында, 10 пунктның 10.1 һәм 10.2.1 пунктчаларында «муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы» сүзләрен «Совет» сүзенә алмаштырырга;

10 пунктның 10.2.2 пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kaibici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин